**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ СТАРОКАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**САРМАН**

**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**ИСКЕ КӘШЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**СОВЕТЫ**

---

РЕШЕНИЕ №10 КАРАР

Иске Кәшер авылы 2020 елнын 03 ноябре

Иске Кәшер авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 20 мартындагы 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Кәшер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Иске Кәшер авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Иске Кәшер авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 20 мартындагы 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.салым түләүчеләр - оешмалар тарафыннан салым аванс белән, узган хисап чорыннан агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталы узганнан соң, җир кишәрлегенең кадастр бәясе процентының тиешле салым ставкасының 1/4 күләмендә түләнә. Салым чоры нәтиҗәләре буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 1 мартыннан да соңга калмыйча түләнә».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3.«Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин рәсми басылган көннән бер айдан да иртәрәк түгел».

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске Кәшер авыл җирлеге Советы Рәисе: Р. Н. Дәүләтҗанов

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ САРМАНОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
Совет Старокаширского сельского поселения
Иске Кәшер авыл җирлеге Советы
ОГРН 10216...
ИНН 1636001259